**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6585**
**09.11.2018**

Яр Чаллы шәһәрендә балалар өчен
Яңа ел чаралары оештыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 пунктның 13 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 маддәсе нигезендә каникул вакытында балаларның ялын оештыру өчен шартлар тудыру максатында

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның финанс идарәсенә Яңа ел чаралары үткәрүгә һәм Яңа ел бүләкләре сатып алуга акча бүлеп бирүне 2018 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының чыгымнарны оптимизацияләү нәтиҗәсендә алынган акчалары хисабына 8 352 160 сум күләмендә, 1, 2, 3 нче кушымталарда каралганча тәэмин итәргә.
2. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка Яр Чаллы шәһәрендә Яңа ел чараларын үткәрүне 3 нче кушымтада каралганча оештырырга.
3. Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе кулланучылар базары бүлегенә Яңа ел бүләкләрен комплектлаштыруны һәм реализацияләүне тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарлары Р.М. Хәлимовка, Н.А. Кропотовага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А.Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин